**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5478**
**23.10.2020**

«Илһамлы каләм» республика конкурсының муниципаль турын оештыру һәм үткәрү турында»

Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, яшь талантларны ачыклау һәм үстерү, эстетик тәрбия бирү, балаларны туган телгә, Габдулла Тукай иҗатына, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасына җәлеп итү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә 2020 елның 27 декабрендә «Илһамлы каләм» республика конкурсының муниципаль турын (алга таба – конкурс) оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауга акча бүлеп бирүне 2020 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» 0709 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 25 000 (егерме биш мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 23 октябрендәге
5478 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Илһамлы каләм» республика конкурсының муниципаль турын үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Илһамлы каләм» республика конкурсының муниципаль туры (алга таба - конкурс) яшь талантларны ачыклау һәм үстерү, балаларны туган телгә, Габдулла Тукай иҗатына, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасына җәлеп итү, эстетик тәрбия бирү, конкурста катнашучыларның башкару осталыгын арттыру максатында үткәрелә.

2. Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү;

2) укучыларны татар прозасына һәм шигъриятенә, татар халкының рухи традицияләренә җәлеп итү;

3) укучыларның татар телендә ирекле аралашу дәрәҗәсен күтәрү;

4) балаларның һәм ата-аналарның игътибарын балалар әдәбиятына һәм укуга җәлеп итү;

5) мәктәп яшендәге балаларның иҗади потенциалын үстерү өчен белем бирү учреждениеләрендә шартлар тудыруга ярдәм итү;

6) балаларда лидерлык сыйфатларын формалаштыру;

7) «Көмеш кыңгырау» газетасында, әдәби җыентыкларда басылган язмалар аша яшь талантларга ярдәм күрсәтү;

8) Яр Чаллы шәһәренең күренекле иҗат интеллигенциясе вәкилләре – Язучылар берлеге әгъзалары белән танышу;

9) шәһәр һәм республика конкурсларында катнашу өчен иҗади сәләтле укучыларны әзерләү.

3. Яр Чаллы шәһәре белем бирү учреждениеләренең татар телен белүче, әдәби яктан аерылып торган 7-11 сыйныфларында укучылар конкурста катнашучылар булып тора ала.

4. Конкурста катнашу ирекле.

5. Конкурста катнашу өчен кандидатларны тәкъдим итү белем бирү учреждениеләре коллективлары һәм ата-аналар тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

7. Оештыру комитеты конкурсның һәр этабында йомгак ясый, шулай ук конкурста җиңүчеләрне билгели.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

8. Конкурс ике этапта үткәрелә.

9. I этап 2020 елның 9 ноябреннән 2020 елның 20 ноябренә кадәр белем бирү учреждениеләрендә үткәрелә.

Конкурсның I этабы йомгаклары буенча II этапта катнашу өчен һәр белем бирү учреждениесеннән берәр катнашучы кертелә.

Иҗат эшләренә карата таләпләр: шигъри әсәрләр – 4-5 дүртъюллыктан, проза, драма әсәрләре 4 биттән артырга тиеш түгел.

Конкурс күрсәтелгән номинацияләр буенча үткәрелә:

1. повесть;
2. хикәя;
3. поэма;
4. шигырь.

10. II этап – муниципаль, 2020 елның 23 ноябреннән 2020 елның 1 декабренә кадәр.

11. Конкурсантларның иҗади эшләрен бәяләүнең төп критерийлары:

1) грамоталы булу, татар әдәби телен белү;
2 теманы ачу;
3) композицион бөтенлек, образларны ачуда нигезлелек;
4) индивидуальлек, иҗади сәләт;
5) ритмика, шигъри әсәрләрнең мелодикасы;
6) әдәби троплардан – метафоралардан, чагыштырулардан, сурәтләүләрдән файдалану.

12. II этап йомгаклары буенча 1, 2, 3 урыннарны алган җиңүчеләр «Илһамлы каләм» республика конкурсында катнашучы була.

13. Конкурсның финалы 2020 елның 25 декабрендә 10.00 сәгатьтә Яр Чаллы шәһәренең «14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесенең театр залында бүләкләү тантанасы рәвешендә булачак.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

14. Конкурста катнашучылар оештыру комитеты тарафыннан бәяләү критерийлары нигезендә ун баллы шкала буенча бәяләнәләр. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

15. 1, 2, 3 урыннарны яулаучылар конкурста җиңүче дип танылa. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2020 елның 23 октябрендәге
5478 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Илһамлы каләм» республика конкурсының муниципаль турына әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Хуҗин Рөстәм Нияз улы | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы |
| 2. | Миначова Наилә Гадел кызы | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе гомуми белем бирү бүлегенең баш белгече |
| 3. | Рәхмәтуллина Наталья Әнвәр кызы | Яр Чаллы шәһәренең «14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе директоры |
| 4. | Сафин Факил Миңнемөхәммәт улы | «Көмеш кыңгырау» республика балалар-яшүсмерләр газетасының баш редакторы (килешү буенча). |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2020 елның 23 октябрендәге
5478 номерлы карарына
3 нче кушымта

«14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге» МАӨББУда
«Илһамлы каләм» республика конкурсының
муниципаль турын үткәрү буенча чыгымнар
сметасы

| Исеме | Саны, берәмлек | Гомуми сумма, сум |
|---|---|---|
| Конкурста җиңүчеләргә призлар<br>2500 сумлык акчалата сертификат | 4 | 10000 |
| Конкурста җиңүчеләргә призлар<br>1500 сумлык акчалата сертификат | 4 | 6000 |
| Конкурста җиңүчеләргә призлар<br>1000 сумлык акчалата сертификат | 4 | 4000 |
| Конкурста җиңүчеләргә призлар<br>500 сумлык акчалата сертификат | 4 | 2000 |
| Конкурста катнашучыларга дипломнар | 75 | 1500 |
| Конкурста җиңүчеләргә призлар<br>(ручкалар) | 75 | 1500 |
| Барлыгы | 166 | 25000,00 |

Барысы: 25 000,00 сум (егерме биш мең сум 00 тиен).

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева